ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

20 декабрь 2024 ел №159

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Монай авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 июнендәге 103 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт серенә даими нигездә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында" 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына «13323» күләмен «13 990» сумга алмаштырырга.
2. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Монай авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 июнендәге 103 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 кушымтада «18260» санын «19173» санына алыштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru « Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә

Монай авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Кириллов